СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.05.2019 — с. Татарское Бурнашево — 62-283

**Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Башлыгы С.В.Бурукинның мәгълүматын тыңлаганнан соң, Бурнаш авыл җирлеге Советы тарафыннан хупланган «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнгән, җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерелгән һәм җирлек халкы белән фикер алышу өчен кирәкле барлык процедуралар да үткәрелгән, дип билгеләп үтә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставының 18, 88 статьялары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставына № 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен расларга.

3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Бурнаш авыл җирлеге Башлыгы** **С.В.Бурукин**

**Бурнаш авыл җирлеге**
**Советының 27.05.2019 елгы**
**62-283 карарына**
**1 нче кушымта**

## Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1.2. Бурнаш авыл җирлеге Уставының 6 статьясының 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөрәҗәгать итү буенча эшчәнлек алып бару».

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Бурнаш авыл җирлеге**
**Башлыгы** **С.В.Бурукин**